Балалар өчен Изге Язма
тәкъдим итә

# Беренче Пасха (Төче күмәч бәйрәме)



Автор: Edward Hughes

Рәсемнәр: Janie Forest
Alastair Paterson

Кемнәр өчен: Lyn Doerksen

Тәрҗемә ителде: www.christian-translation.com

Гамәлгә ашырылды: Bible for Children
www.M1914.org

©2020 Bible for Children, Inc.
Лицензия: Сезнең бу хикәят текстын, сату хокукыннан башка гына, күчермә итеп яки бастырып алу хокукыгыз бар.

Туа янында бер хатын-кыз басып тора, аның моңсу күзләре ерактан гына канкойгыч манзараны күзәтә. Аның улы үлем тозагында.  Анасы – Мәрьям, һәм ул Гайсә хачка кадакланган урында басып тора.





Ничек шулай килеп
чыкты соң әле? Гайсәнең
гүзәл гомере ни өчен шул
рәвешле начар
тәмамлана?
Раббыбыз
ни өчен моңа
юл куя, Улын
хачка кадаклатып, һәлак
итә? Гайсә әллә соң
Үзенең кем булуында
ялгышканмы, Раббы
Алла уңышсызлыкка
тарыганмы?



Юк! Аллаһы уңышсызлыкка тарымаган. Гайсә бернинди дә ялгышлык кылмаган. Гайсә үзенең әшәке кешеләр тарафыннан үтереләчәге турында һәрвакыт белеп яши. Әле Гайсә сабый чакта ук Шимон исемле карт Мәрьямгә киләчәктә кайгы булачагы турында әйткән була.



Гайсә үтерелергә
берничә көн кала,
аның янына бер
хатын-кыз килә һәм
аякларына хуш исле
май сала. – Ул акчасын
юкка сарыф итә, - дип әйтә аңа
шәкертләре бу хакта. – Ул хатын
Минем өчен яхшы эш эшләде, Мине Күмәргә
әзерләде, - дип әйтә Гайсә. Нинди сәер сүзләр!

Шуннан соң Гайсәнең унике шәкерте арасыннан Яһүд дигәне, утыз көмеш тәңкә хисабына Гайсәне баш руханиларга тапшырып, аңа хыянәт итәргә ризалаша.





Яһүдләрнең Пасха (Төче күмәч) бәйрәмендә Гайсә соңгы мәртәбә шәкертләре белән ашарга утыра. Аларга Аллаһы һәм Үзен яратучы бәндәләре өчен вәгъдә ителгән әҗерләр хакында шаккатыргыч әйберләр сөйли.



Шуннан Гайсә, икмәк алып, аны сындырып, һәм касә алып, аны да шәкертләренә бирә. Шуннан ашап-эчегез, ди. Бу әйберләр, гөнаһлар кичерелсен өчен, аларга Гайсәнең тәне белән Каны бирелгәнлеге турында искәртеп торырга тиеш була.



Шул чакта Гайсә шәкертләренә, сез миңа хыянәт итәрсез һәм качып китәрсез, ди.  Петер аңа: “Мин беркайчан да сиңа ышанычымны югалтмам!” - дип әйтә.  “Әтәч кычкырганчы, син Миннән өч тапкыр ваз кичәчәксең”, - дип әйтә аңа Гайсә.





Соңрак, шул ук кичтә Гайсә, дога кылырга дип, Гетсимәни бакчасына юл ала. Аның шәкертләре йокыга тала. “Атам, әгәр мөмкин булса, - дип дога кыла Гайсә, - Мине бу газаплар касәсеннән арындырчы! Хәер, Мин теләгәнчә түгел, ә Син теләгәнчә булсын”.

Кинәт бакчага бик күп кеше җыела, аларны Яһүд алып килә. Гайсә карышмый. Ләкин Петер кылычы белән бер кешенең колагын кисә. Гайсә бу кеше колагына кулын тидереп, аны терелтә.

Гайсә белә, Аның кулга алынуы Раббысы тәкъдиреннән бер өлеше булып тора.



Гайсәне тотып алып, иң баш рухани өенә алып киләләр. Андагы яһүд идарәчеләре, Гайсә үләргә тиеш, дип әйтә. Петер яшәнә, ишегалдындагы учак янында хезмәтчеләр белән җылынып басып тора, барган хәлләрне күзәтә.



Кешеләр өч мәртәбә Петерга төртеп: “Син Гайсә белән идең бит!” - дип әйтәләр. Петер өч тапкырда да моны инкарь итә. Гайсә бу хакта алдан ук әйткән була бит инде. Петер, Гайсәне белмим, дип Аллаһы белән ант итә.



# КИ-КЕ-РИ-КҮК



Шулвакыт әтәч кычкырып җибәрә. Петер өчен бу, әйтерсең лә, Аллаһы билгесе була. Гайсә әйткәннәрне исенә төшереп, Петер елап җибәрә.



Яһүд дә үкенә.
Ул бит Гайсәнең бернинди гөнаһ та, җинаять тә кылмавын, гаепле булмавы хакында белә.
Яһүд 30 көмеш тәңкәне кире кайтара, ләкин руханиларның бу акчаны аласы килми.


Яһүд акчаны
җиргә ташлап,
асылынып үлә.



Руханилар Гайсәне Рим идарәчесе Пилат янына алып килә. “Мин бу Кешене гаеплләрлек бер сәбәп тә күрмим”, - дип әйтә Пилат. Ләкин халык бертавыштан: “Хачка кадакла Аны, хачка!” – дип таләп итә.

Ахыр чиктә Пилат алар теләгәнчә карар чыгара. Гайсәне хачка кадаклап үтерергә куша. Гаскәриләр Гайсәне йодрыклары белән тукмый, аның битенә төкерә һәм каеш белән кыйныйлар. Башына чәнечкеле ботаклардан үрелгән таҗ кидертеп куялар. Шуннан, үлсен дип, агач хачка кадаклыйлар.





Гайсә үзенең нәкъ шушы рәвешле үләчәге турында һәрвакыт белеп яши. Үзенә инанган кешеләр өчен Үзенең һәлак ителүе аша гөнаһлары кичереләчәге турында да белә Ул. Гайсә белән бергә ике җинаятьче дә үтерелә. Аларның берсе Гайсәгә иман китерә һәм җәннәткә эләгә. Ә икенчесе – юк.



Берничә сәгать җәзаланганнан соң Гайсә: “Булды”, - дип әйтә һәм үлә.  Аның тәкъдире үтәлгән була.  Дуслары аны мәгарәдә, таштан уеп ясалган кабергә күмә.



Шуннан Рим гаскәриләре
кабер авызын томалап,
каберне сагалап тора.
Анда хәзер беркем
дә үтеп керә, чыга
да алмый.




Ләкин хикәят шуның белән
генә тәмамланып китсә,
кызык булмас иде.
Аллаһы кодрәте
белән Гайсә
үледән тере
була!

Атнаның беренче көнендә, таң ату белән, Гайсәнең кайбер шәкертләре кабер авызын томалап торган ташның аударылган булуын күреп ала.  Эчкә кереп карасалар, анда Гайсә юк.



Бер хатын елый-елый кабер янында калган була. Аның янына Гайсә килә! Ул бу хакта шәкертләргә сөйләр өчен, сөенә-сөенә кайтып китә. “ГАЙСӘ ИСӘН! ГАЙСӘ ҮЛЕП ТЕРЕЛДЕ!”



Тиздән Гайсә шәкертләре янына килә һәм тырнактан яраланган кул яраларын күрсәтә. Бу хак дөреслек була. ГАЙСӘ ҮЛЕП ТЕРЕЛӘ! Ул үзенә хыянәт иткән Петерны кичерә һәм шәкертләренә бөтен Җир йөзендә Үзе хакында сөйләргә боера. Шуннан ул янә Күкләр Патшалыгына әйләнеп кайта.

Беренче Пасха (Төче күмәч бәйрәме)

Аллаһы Сүзеннән, Изге Язмадан хикәят

урнашкан

Маттай 26-28, Лук 22-24,
Яхъя 13-21

“Сүзләреңнең күренүе балаларны яктыртып акыллыландыра.” Мәдхия 119:130

# Тәмам

Әлеге Изге Язма хикәятендә Җир йөзендәге барча тереклекне бар кылган һәм Үзенә иман китерүебезне теләгән кодрәтле Аллаһы турында бәян ителә.

Раббыбыз начар гамәлләр кылуыбыз турында белеп тора, Ул аларны гөнаһ дип атый. Гөнаһның җәзасы – үлем. Ләкин Аллаһы сезне шулкадәр ярата ки, гөнаһларыгыз өчен җәзаланырга дип бердәнбер Улы Гайсәне хачта үтертү өчен җибәрде. Шуннан соң Гайсә үлеп терелде һәм Күккә ашты! Гайсәгә ышансагыз, гөнаһларыгызны кичерүе турында сорагыз, Ул моны эшләр! Ул килер һәм сездә яшәр, һәм сез дә мәңге Аның белән бергә булырсыз.

Моның хак булуына ышансагыз, Аллаһыга болай диегез: Хөрмәтле Гайсә, Синең Раббы булуыңа һәм гөнаһларым хакына һәлак ителү өчен кеше булып яралтылуыңа һәм хәзерге вакытта исән булуыңа ышанамын. Зинһар өчен, тормышыма үтеп кер, мин яңа тормыш башлап, кайчан да булса Синең белән мәңге бергә була алсын өчен, гөнаһларымны ярлыка. Балаң күк, Сиңа сәҗдә кылып, Сиңа иман китереп яшәргә ярдәм ит. Амин.

Изге Язма укы һәм көн саен Аллаһы юлында бул! (Яхъя 3:16)